ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 15.11.2024 1815 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 23 апрелендәге 353 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Министрлар Кабинетының 2022 елның 18 ноябрендәге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 23 апрелендәге 353 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләр билгеләнә:

- эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 2 510 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү, әмма айга 2 510 сумнан да артмаган күләмдә;

- хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 100 000 сум күләмендә.».

2. Әлеге карарны рәсми бастырып чыгарырга һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН